| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН<br>ГЛАВА АМЗИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ӘМЗӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Яңа Әмзә ав **КАРАР**

«29» март 2024 ел № 5

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Кызыл Юл поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2024 елның 11 апрелендә 13 сәгать 00 минутта Кызыл Юл поселогы, Гагарин урамы, 15нче йорт адресы буенча урнашкан Биләр урманчылыгы конторасы бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Кызыл Юл поселогында үзара салым кертү, элек расланган карарларга үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлегенең Кызыл Юл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 15 ноябрендәге 3 номерлы карары;
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлегенең Кызыл Юл торак пунктында гражданнар Җыенының 15.11.2023 ел, № 4 карары.

2. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

3.1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлегенең Кызыл Юл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 15.11.2023 ел, № 3 номерлы карарның 1 пунктына үзгәрешләр кертергә ризамы, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлегенең Кызыл Юл торак пунктында гражданнар җыены узган дип таныйрга, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип таныйрга.

"2024 елда Әмзә авыл җирлегенең Кызыл Юл бистәсе территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү ризамы?" дигән сорау буенча карарны таныйрга:

1) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Кызыл Юл торак пунктында янгынга каршы гидрант сатып алу һәм урнаштыру).

3.2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлегенең Кызыл Юл торак пунктында гражданнар Җыенының 15.11.2023 ел, №4 карарына үзгәрешләр кертергә ризамы, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп::

1. 2024 елда Әмзә авыл җирлегенең Кызыл Юл бистәсе территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Кызыл Юл торак пунктында янгынга каршы гидрант сатып алу һәм урнаштыру).

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кызыл Юл поселогы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әмзә авыл җирлеге башлыгы Ә.Ф.Сафиуллина